**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани , дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы., 6 нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» декабрь 2025 ел** **№ 15**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 14.09.2022 № 135 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында»гы 2025 елның 25 ноябрендәге № 996 карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 14.09.2022 ел №135 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» гы нигезләмәгә (Әтнә район Советының 18.11.2022 №145, 27.01.2023 №165, 15.05.2024 №230, 16.11.2024 №246, 25.04.2025 №276 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның 4 абзацында «15389» саннарын «16928» саннарына алмаштырырга;

2. Әлеге карарның 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш.Хисамиев